КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 30 ноябрь г.Казань № 1268

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 25 сентябрь, 853 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 25 сентябрь, 853 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 6 май, 380 нче; 2020 ел, 16 апрель, 294 нче; 2020 ел, 1 сентябрь, 768 нче; 2020 ел, 3 ноябрь, 989 нчы; 2021 ел, 21 июль, 633 нче; 2021 ел, 26 июль, 645 нче; 2021 ел, 30 октябрь, 1030 нчы; 2022 ел, 26 май, 489 нчы; 2022 ел, 20 июнь, 587 нче; 2022 ел, 14 сентябрь, 1002 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасында дәүләт спорт әзерлеге үзәкләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

I бүлекнең 1 пунктында «хезмәткәрләрнең окладлары» сүзләреннән соң «(дәүләт спорт әзерлеге үзәкләреннән тыш)» сүзләрен өстәргә;

1 нче таблицага түбәндәге эчтәлекле пункт өстәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «88. | Флорбол | 1,5 | 2,2 | 3,2 | 5,6 | 5,6 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 17,0 | 20,0 | 25,0»; |

2 нче таблицага түбәндәге эчтәлекле 88 пункт өстәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «88. | Флорбол | 4 | 6 | 8 | 12 | 12 | 18 | 18 | 18 | 20 | 22 | 24»; |

3 нче таблицага түбәндәге эчтәлекле 88 пункт өстәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «88. | Флорбол | 15 | 15 | 14 | 12 | 12 | 10 | 10 | 10 | 6 | 5 | 3»; |

7 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7 нче таблица

Бер шөгыльләнүче өчен ярышларда биләгән урын нигезендә югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен адаптив физик культура буенча тренерларның, өлкән тренер-укытучыларның хезмәте өчен түләү нормативлары

(процент)

| Ярышлар дәрәҗәсе | Биләнгән урын | Хезмәт өчен түләү нормативлары | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | спортның олимпия, паралимпия, сурдлимпия төрләре; олимпия, паралимпия, сурдлимпия дисциплиналары | | олимпия булмаган спорт төрләре, олимпия булмаган дисциплиналар; паралимпия булмаган, сурдлимпия булмаган дисциплиналар | |
| | | шәхси | командалы | шәхси | командалы |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| Олимпия уеннары, Паралимпия уеннары, Сурдлимпия уеннары | 1 | 500,0 | 500,0 | - | - |
| | 2 | 375,0 | 375,0 | - | - |
| | 3 | 250,0 | 250,0 | - | - |
| | 4 | 200,0 | 200,0 | - | - |
| | 5 | 188,0 | 188,0 | - | - |
| | 6 | 125,0 | 125,0 | - | - |
| | катнашу | 63,0 | 63,0 | - | - |
| Дөнья чемпионаты | 1 | 75,0 | 75,0 | 52,5 | 37,5 |
| | 2 | 70,0 | 70,0 | 50,0 | 35,0 |
| | 3 | 65,0 | 65,0 | 47,5 | 32,5 |
| | 4 | 60,0 | 60,0 | 45,0 | 30,0 |
| | 5 | 55,0 | 55,0 | 42,5 | 27,5 |
| | 6 | 50,0 | 50,0 | 35,0 | 25,0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| Дөнья Кубогы, Европа чемпионаты | 1 | 70,0 | 70,0 | 50,0 | 35,0 |
| | 2 | 65,0 | 65,0 | 45,0 | 32,5 |
| | 3 | 60,0 | 60,0 | 42,5 | 30,0 |
| | 4 | 55,0 | 55,0 | 37,5 | 27,5 |
| | 5 | 50,0 | 50,0 | 35,0 | 25,0 |
| | 6 | 45,0 | 45,0 | 32,5 | 22,5 |
| | 7 – 12 | 15,0 | 15,0 | 12,5 | 7,5 |
| Ир-атлар һәм хатын-кызлар арасында рәсми халыкара ярышлар | 1 | 20,0 | 20,0 | 10,0 | 10,0 |
| | 2 | 17,5 | 17,5 | 8,8 | 8,8 |
| | 3 | 15,0 | 15,0 | 2,5 | 7,5 |
| Европа Кубогы | 1 | 60,0 | 60,0 | 42,5 | 30,0 |
| | 2 | 55,0 | 55,0 | 37,5 | 27,5 |
| | 3 | 50,0 | 50,0 | 35,0 | 25,0 |
| | 4 | 45,0 | 45,0 | 32,5 | 22,5 |
| | 5 – 10 | 22,5 | 22,5 | 20,0 | 11,3 |
| Бөтендөнья универсиада | 1 | 45,0 | 45,0 | 32,5 | 22,5 |
| | 2 | 40,0 | 40,0 | 27,5 | 20,0 |
| | 3 | 35,0 | 35,0 | 22,5 | 17,5 |
| | 4 – 6 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 10,0 |
| Россия чемпионаты | 1 | 50,0 | 17,5 | 35,0 | 8,8 |
| | 2 | 45,0 | 15,0 | 32,5 | 7,5 |
| | 3 | 40,0 | 12,5 | 27,5 | 6,3 |
| | 4 | 35,0 | 10,0 | 25,0 | 5,0 |
| Россия Кубогы | 1 | 40,0 | 15,0 | 27,5 | 7,5 |
| | 2 | 35,0 | 12,5 | 22,5 | 6,3 |
| | 3 | 30,0 | 10,0 | 20,0 | 5,0 |
| | 4 | 25,0 | 8,5 | - | 4,3 |
| Федераль округ чемпионаты | 1 | 25,0 | 7,5 | 22,5 | 3,8 |
| | 2 | 20,0 | 7,0 | 18,0 | 3,5 |
| Татарстан Республикасы чемпионаты | 1 | 10,0 | 3,5 | 5,0 | 1,8 |
| Россия беренчелеге (яшьләр, юниорлар) | 1 | 35,0 | 7,3 | 30,0 | 3,7 |
| | 2 | 30,0 | 6,8 | 25,0 | 3,4 |
| | 3 | 25,0 | 6,3 | 22,5 | 3,2 |
| | 4 | 20,0 | 5,8 | 20,0 | 2,9 |
| | 1 | 35,0 | 7,3 | 30,0 | 3,7 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| Бөтенроссия универсиада | 2 | 30,0 | 6,8 | 25,0 | 3,4 |
| | 3 | 25,0 | 6,3 | 22,5 | 3,2 |
| | 4 | 20,0 | 5,8 | 20,0 | 2,9 |
| Дөнья, Европа беренчелеге | 1 | 45,0 | 45,0 | 32,5 | 22,5 |
| | 2 | 40,0 | 40,0 | 27,5 | 20,0 |
| | 3 | 35,0 | 35,0 | 22,5 | 17,5 |
| | 4 – 6 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 10,0 |
| Бөтендөнья яшьләр уеннары | 1 | 45,0 | 45,0 | 32,5 | 22,5 |
| | 2 | 40,0 | 40,0 | 27,5 | 20,0 |
| | 3 | 35,0 | 35,0 | 22,5 | 17,5 |
| | 4 – 6 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 10,0 |
| Европа яшьләр фестивале | 1 | 40,0 | 40,0 | 20,0 | 20,0 |
| | 2 | 35,0 | 35,0 | 17,5 | 17,5 |
| | 3 | 30,0 | 30,0 | 15,0 | 15,0 |
| | 4 – 6 | 20,0 | 20,0 | 10,0 | 10,0 |
| Юниорлар, юниоркалар, егетләр, кызлар, малайлар, кыз балалар арасында рәсми халыкара ярышлар | 1 | 22,5 | 15,0 | 15,0 | 15,0 |
| | 2 | 20,0 | 12,5 | 12,5 | 12,5 |
| | 3 | 17,5 | 10,0 | 10,0 | 10,0 |
| | 4 | 15,0 | 7,5 | 7,5 | 7,5 |
| Россия беренчелеге (егетләр, кызлар, малайлар, кыз балалар) | 1 | 35,0 | 6,0 | 18,0 | 3,0 |
| | 2 | 28,0 | 5,5 | 14,0 | 2,7 |
| | 3 | 20,0 | 5,0 | 10,0 | 2,5 |
| Россия яшьләренең Спартакиада финалы | 1 | 37,5 | 7,5 | 32,5 | 3,8 |
| | 2 | 32,5 | 7,0 | 27,5 | 3,5 |
| | 3 | 27,5 | 6,5 | 22,5 | 3,3 |
| | 4 – 6 | 25,0 | 6,0 | 20,0 | 3,0 |
| Россия укучыларының Спартакиада финалы | 1 | 37,5 | 7,5 | 32,5 | 3,8 |
| | 2 | 30,0 | 7,0 | 25,0 | 3,5 |
| | 3 | 27,5 | 6,5 | 22,5 | 3,3 |
| | 4 – 6 | 22,5 | 6,0 | 18,0 | 3,0 |
| Россия Федерациясе Спорт Министрлыгының бердәм календарь планына кертелгән бөтенроссия ярышлары | 1 | 15,0 | 5,0 | 7,5 | 2,5 |
| | 2 | 12,5 | 2,5 | 6,8 | 1,3 |
| | 3 | 10,0 | 2,0 | 5,0 | 0,8 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| Идел буе федераль округы беренчелеге | 1 | 20,0 | 5,8 | 10,0 | 2,9 |
| | 2 | 17,5 | 5,3 | 9,0 | 2,7 |
| | 3 | 15,0 | 4,8 | 7,5 | 2,4 |
| Олимпия резервы дәүләт училищесына укырга керү | - | 25,0 | 25,0 | - | -»; |

IV бүлекнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Спортның кайбер төрләренә (төп тренердан башка) спортчылар белән бер үк вакытта эшләү шарты белән катнаш спорт төрләре (акробатика, хореография һ.б.) буенча тренерлар җәлеп ителергә мөмкин. Аларның хезмәте өчен түләү әлеге Нигезләмәнең 1 нче таблицасы нигезендә төп тренерларның хезмәте өчен түләү нормативлары буенча эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә гамәлгә ашырыла, әмма ул төп тренер өчен каралган хезмәт өчен түләү нормативының яртысыннан артмаска тиеш.»;

VII бүлекнең 4 пунктындагы алтынчы абзацында «3,5» саннарын «20,0» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләү гамәлгә ашырыла торган дәүләт физкультура спорт оешмаларында эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазиыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

IV бүлектә:

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр.»;

түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

«6. Хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләү гамәлгә ашырыла торган дәүләт физкультура спорт оешмаларында эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрлә-ренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$B_{it} = O_d \times D_{it},$$

монда:

$B_{it}$ – хезмәт интенсивлыгы өчен түләү;

$O_d$ – Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләү гамәлгә ашырыла торган дәүләт физкультура спорт оешмаларында эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре вазыйфаи оклады;

$D_{it}$ – хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә түләү күләме.

Хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә түләүләр күләмнәре әлеге Нигезләмәгә теркәлгән кушымтаның 2 нче таблицасында китерелде.»;

әлеге Нигезләмәнең кушымтасында:

Стимуллау характерындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автоном республикаларның дәүләт бүләкләре исемлеге итеп 1 нче таблицаны санарга;

түбәндәге эчтәлекле 2 нче таблица өстәргә:

«2 нче таблица

Татарстан Республикасының дәүләт физик культура һәм спорт оешмаларында эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә түләүләр күләмнәре

| Татарстан Республикасының дәүләт физик культура һәм спорт оешмалары исемнәре | Һөнәри квалификация төркемнәре исеме | Өстәмә түләү күләме, процент |
|---|---|---|
| «Спорт әзерлеге үзәге» дәүләт автоном учреждениесе | җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре | 50,0»; |

әлеге карарга Татарстан Республикасында дәүләт спорт әзерлеге үзәкләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне (карарга теркәлә) өстәргә.

2. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 30 ноябрь, 1268 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасында дәүләт спорт әзерлеге үзәкләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмә

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасында дәүләт спорт әзерлеге үзәкләрендә (алга таба – спорт әзерлеге үзәкләре) хезмәткәрләре окладларын формалаштыру тәртибен, компенсация һәм стимуллау характерындагы түләүләр шартларын һәм күләмнәрен, шулай ук аларны билгеләү критерийларын билгели.

2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр кулланыла:

хезмәт өчен түләү системасы – спорт әзерлеге үзәкләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартларын һәм күләмнәрен (база (вазыйфаи) окладлары күләмнәрен кертеп), шулай ук Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнгән компенсацияләү һәм стимуллау характерындагы түләүләр билгеләнә торган нормалар җыелмасы;

база окладлары – компенсация, стимуллау түләүләрен исәпкә алынмыйча, эшчәнлеге тиешле һөнәри квалификация төркеменә керә торган спорт әзерлеге үзәкләре хезмәткәрләренең оклады, хезмәт хакы ставкасы;

вазыйфаи оклад – спорт әзерлеге үзәкләре хезмәткәрләренең компенсация, стимуллау түләүләре исәпкә алынмаган, фактта эшләнгән вакыт өчен бер календарь айга билгеле бер катлаулылыктагы хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәгән хезмәте өчен түләүнең үзгәрми торган күләме;

спорт әзерлеге үзәкләре хезмәткәрләренең хезмәт хакы (хезмәте өчен түләү) – хезмәткәрнең квалификациясенә, башкарыла торган эшнең катлаулылыгына, күләменә, сыйфатына һәм шартларына карап, хезмәт өчен бүләкләү (компенсация һәм стимуллау түләүләрен кертеп);

компенсация характерындагы түләүләр – компенсация характерындагы өстәмәләр һәм өстәмә түләүләр (шул исәптән нормаль булмаган шартларда эшләгән өчен) һәм компенсация характерындагы башка түләүләр;

стимуллау характерындагы түләүләр – стимуллау характерындагы өстәмәләр һәм өстәмә түләүләр, премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре.

3. Спорт әзерлеге үзәкләре хезмәткәрләренең хезмәт хакы (хезмәте өчен түләү) түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:

вазыйфаи окладлар;

стимуллау характерындагы түләүләр;

компенсация характерындагы түләүләр.

4. Ел саен бирелә торган яки башка ялда булган чорда, вакытлыча хезмәткә яраксыз булган чорда, шулай ук хезмәткәрнең уртача эш хакы саклана торган башка чорларда спорт әзерлеге үзәкләре хезмәткәрләренең профиль буенча эш стажы

артуга, белем алуга яки белем турында документларны торгызуга, квалификация категориясе бирүгә, дәүләт бүләге бирүгә, ведомство мактау билгеләре белән бүләкләнүгә бәйле рәвештә хезмәт өчен түләү күләме үзгәрү хокукы барлыкка килгәндә, аның хезмәте өчен түләү күләменә үзгәреш кертү әлеге чорлар тәмамланганнан соң гамәлгә ашырыла.

5. Спорт әзерлеге үзәкләре җитәкчеләре:

белем алу һәм эш (белгечлек буенча, билгеле бер вазыйфада эшләү) стажы турындагы документларны һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәре билгеләнә торган башка нигезләрне тикшерә;

ел саен спорт әзерлеге үзәкләре хезмәткәрләре өчен тарификацияле исемлекләр төзи һәм аларны раслый;

спорт әзерлеге үзәкләре хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләмнәрен үз вакытында һәм дөрес билгеләү өчен җавап бирә.

## II. Спорт әзерлеге үзәкләре хезмәткәрләренең база окладларын билгеләү

1. Спорт әзерлеге үзәкләрендә медицина хезмәткәрләре (алга таба – медицина хезмәткәрләре) вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | 1 айга база оклады күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Медицина статистигы | 16 200 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Шәфкать туташы | 17 200 |
| | Массаж буенча шәфкать туташы | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Фельдшер | 17 900 |
| «Табиблар һәм провизорлар» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән табиб-белгечләрдән башка) | 20 600 |
| «Учреждениеләрдәге структур бүлекчәләрнең югары медицина һәм фармацевтика белемле җитәкчеләре (табиб-белгеч, провизор)» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлекчә (бүлек, бүлекчә, лаборатория, кабинет, отряд һ.б.) башлыгы | 23 400 |

2. Спорт әзерлеге үзәкләренең физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазыйфаларының (алга таба – физик культура һәм спорт хезмәткәрләре) һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | 1 айга база оклады күләме, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем (белем турында раслый торган документ булганда) | бакалавр, белгеч яки магистр дипломы белән раслана торган югары белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Икенче дәрәҗә физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Спортчы-инструктор | 15 279 | | |
| | Күнекмәләр ясау барышы администраторы | - | 16 149 | 18 382 |
| | Физкультура-спорт оешмалары инструктор-методисты | - | 16 149 | 18 382 |
| | Адаптацияли торган физик культура буенча инструктор-методист | - | 16 149 | 18 382 |
| | Тренер | - | 16 149 | 18 382 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | Адаптив физик культура буенча тренер-укытучы | | 16 149 | 18 382 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Адаптив физик культура буенча өлкән инструк-тор-методист | - | 16 155 | 18 394 |
| | Физкультура-спорт оешмала-рының өлкән инструктор-методисты | - | 16 155 | 18 394 |
| Өченче дәрәҗә физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квали-фикация дәрә-җәсе | Аналитик (спорт төре яки төрләр төркеме буенча) | - | - | 18 562 |
| Дүртенче дәрәҗә физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Спорт җыелма командасының баш тренеры (спорт төре буенча) | | | 20 600 |
| | Идарә башлыгы (спорт төре яки төрләр төркеме буенча) | | | 20 600 |

## III. Спорт әзерлеге үзәкләре хезмәткәрләренең вазыйфаи окладын формалаштыру тәртибе

1. Спорт әзерлеге үзәкләренең медицина хезмәткәрләре, физик культура һәм спорт хезмәткәрләренең вазыйфа оклады түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$O_d = O_b \times S,$$

монда:

$O_d$ – спорт әзерлек үзәкләре хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$O_b$ – әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган хезмәткәрләрнең база оклады күләме;

S – ставкаларның факттагы саны.

## IV. Стимуллау характерындагы түләүләр

1. Стимуллау характерындагы түләүләргә хезмәткәрне сыйфатлы хезмәт нәтиҗәсенә стимуллауга, шулай ук башкарылган эш өчен бүләкләүгә юнәлдерелгән түләүләр керә.

1.1. Стимуллау характерындагы түләүләргә түбәндәгеләр керә:

квалификация категориясе өчен түләүләр;

эшчәнлекнең үзенчәлеклеге өчен түләүләр;

эш нәтиҗәләре югары булган өчен түләүләр;

спорт исемнәре, спорт разрядлары өчен түләүләр;

дәүләт бүләкләренә ия булган өчен түләүләр;

профиль буенча эш стажы өчен түләүләр;

хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр;

премияләр һәм башка бүләкләү түләүләре;

башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр.

2. Спорт әзерлеге үзәкләренең медицина хезмәткәрләренә стимуллау характерындагы түләүләр күләме һәм аларны билгеләү тәртибе.

2.1. Квалификация категориясе өчен түләүләр һөнәри квалификация төркемнәре яктылыгында аттестация йомгаклары буенча квалификация категорияләре бирүнең тариф-квалификация тасвирнамәләре нигезендә карала торган белгечлекләр буенча эшләүче хезмәткәрләргә бирелә. Квалификация категориясе өчен түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$B_{kk} = O_d \times D_{kk},$$

монда:

$B_{kk}$ – квалификация категориясе өчен түләүләр;

$O_d$ – спорт әзерлек үзәкләре хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{kk}$ – 1 нче таблицада китерелгән квалификация категориясе өчен өстәмә түләү күләме.

Квалификация категориясе өчен түләүләрне үзгәртү (билгеләү) аттестация комиссиясе төзелгән орган (учреждение) боерыгы датасы нигезендә башкарыла.

1 нче таблица

Квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме

| Квалификация категориясе | Өстәмә түләү күләме, процент |
|---|---|
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | |
| Икенче квалификация категориясе | 3,0 |

| | |
|---|---|
| Беренче квалификация категориясе | 6,0 |
| Югары квалификация категориясе | 10,0 |
| Табиблар һәм провизорлар вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | |
| Икенче  квалификация категориясе | 6,0 |
| Беренче квалификация категориясе | 10,0 |
| Югары квалификация категориясе | 20,0 |

2.2. Эшчәнлекнең үзенчәлеклеге өчен түләүләр спорт әзерлеге үзәкләрендә эшләүче медицина хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$B_{sd} = O_d \times D_{sd},$$

монда:
$B_{sd}$ – эшчәнлекнең үзенчәлеклеге өчен түләүләр;
$O_d$ – спорт әзерлек үзәкләре хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;
$D_{sd}$ – эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен 16,2 процентка тигез итеп кабул ителә торган өстәмә түләү күләме.

2.3. Спорт әзерлеге үзәкләрендә һәм бүлекчәләрендә конкрет эш шартларын исәпкә алып, эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмә түләүләр билгеләнә торган хезмәткәрләр вазыйфалары исемлеге, сайлап куелган һөнәр берлеге органы яки хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен тәкъдим итәргә вәкаләтле орган белән килештереп, һәр учреждение тарафыннан раслана.

2.4. Дәүләт бүләкләренә ия булган өчен түләүләр медицина хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$B_{pz} = O_d \times D_{pz},$$

монда:
$B_{pz}$ – дәүләт бүләкләренә ия булган өчен түләү;
$O_d$ – спорт әзерлек үзәкләре хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;
$D_{pz}$ – дәүләт бүләкләренә ия булган өчен өстәмә түләү күләме.

Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикаларның дәүләт бүләкләренә ия булган өчен өстәмә түләү күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның дәүләт бүләкләренә ия булган өчен өстәмә түләү күләме 7 процентны тәшкил итә.

Спорт әзерлеге үзәкләренең медицина хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирелә торган дәүләт бүләкләре исемлеге әлеге Нигезләмәгә кушымтаның 1 нче таблицасында китерелде.

2.5. Дәүләт бүләкләренә ия булган өчен түләү күләмнәрен билгеләү дәүләт бүләге бирелгән көннән алып башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк дәүләт

бүләкләренә ия булган хезмәткәрләргә аларга ия булган өчен түләү хезмәткәрнең сайлавы буенча дәүләт бүләкләренең берсе буенча билгеләнә.

2.6. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр, профиль буенча эш озынлыгына карап, һөнәри квалификация төркемнәре яктылыгында стаж буенча төркемнәр нигезендә билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$B_s = O_d \times D_{sr},$$

монда:

$B_s$ – профиль буенча эш стажы өчен түләү;

$O_d$ – спорт әзерлек үзәкләре хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{sr}$ – профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме 2 нче таблицада китерелде.

2 нче таблица

Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләмнәре

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Стаж буенча төркем | Өстәмә түләү күләме, процент |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы | 3 елдан 5 елга кадәр | 2,5 |
| | 5 елдан 10 елга кадәр | 3,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 4,5 |
| | 15 елдан артыграк | 5,5 |
| Табиблар һәм провизорлар | 3 елдан 5 елга кадәр | 5,0 |
| | 5 елдан 10 елга кадәр | 7,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 9,0 |
| | 15 елдан артыграк | 10,0 |

2.7. Эш стажы үзгәргәндә, профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен билгеләү (үзгәртү), әгәр стажны раслый торган документлар оешмада булганда, профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен арттыру хокукын бирә торган стажга ирешкән көннән яки стажны раслый торган кирәкле документны тапшырган көннән алып башкарыла.

2.8. Хезмәтнең интенсивлыгы өчен түләүләр урта медицина һәм фармацевтика персоналы, табиблар һәм провизорлар вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә вазыйфалар буенча бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$B_{sr} = O_d \times D_{sr},$$

монда:
$B_{sr}$ – хезмәт нәтиҗәлелеге өчен түләүләр;
$O_d$ – спорт әзерлек үзәкләре хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;
$D_{sr}$ – 3 нче таблицада китерелгән хезмәт киеренкелеге өчен өстәмә түләү күләме.

3 нче таблица

Хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә түләүләр күләмнәре

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Өстәмә түләүләр диапазоны, процент |
|---|---|---|
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы | икенче | 1,5 |
| | өченче | 3,0 |
| | дүртенче | 4,5 |
| | бишенче | 10,0 |
| Табиблар һәм провизорлар | беренче – икенче | 5,0 |

3. Спорт әзерләге үзәкләренең физик культура һәм спорт хезмәткәрләренә стимуллау характерындагы түләүләр билгеләү күләмнәре һәм тәртибе.

3.1. Квалификация категориясе өчен түләүләр спорт әзерлеге үзкләренең физик культура һәм спорт хезмәткәрләренә аларның квалификация категориясе гамәлдә булу срогы чикләрендә квалификация категориясе гамәлдә булганда бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$B_{kk} = O_d \times D_{kk},$$

монда:
$B_{kk}$ – квалификация категориясе өчен түләүләр;
$O_d$ – спорт әзерлек үзәкләре хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;
$D_{kk}$ – 4 нче таблицада китерелгән квалификация категориясе өчен өстәмә түләү күләме.

4 нче таблица

Квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме

| Квалификация дәрәҗәсе | Квалификация категориясе | Өстәмә түләү күләме, процент |
|---|---|---|
| Икенче дәрәҗә физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | беренче квалификация категориясе | 5,0 |
| | югары квалификация категориясе | 6,0 |
| Икенче | беренче квалификация категориясе | 11,0 |
| | югары квалификация категориясе | 13,0 |
| Өченче | беренче квалификация категориясе | 11,0 |
| | югары квалификация категориясе | 13,0 |
| Өченче дәрәҗә физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | беренче квалификация категориясе | 11,0 |
| | югары квалификация категориясе | 13,0 |
| Дүртенче дәрәҗә физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | беренче квалификация категориясе | 11,0 |
| | югары квалификация категориясе | 13,0 |

Квалификация категориясе өчен түләүләрне билгеләү (үзгәртү) тиешле аттестация комиссиясе тарафыннан уңай карар кабул ителгән көннән гамәлгә ашырыла.

3.2. Эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләр беренче, икенче, өченче һәм дүртенче дәрәҗәләрдәге физик культура хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$B_{sd} = O_d \times D_{sd} \times \frac{H_{f_{sd}}}{H_n},$$

монда:

$B_{sd}$ – эшчәнлекнең үзенчәлеклеге өчен түләүләр;

$O_d$ – спорт әзерлек үзәкләре хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлы;

$D_{sd}$ – олимпия резервындагы махсуслаштырылган оешмаларда (бүлекләрдә) эшчәнлек үзенчәлеге өчен 7 процентка тигез итеп кабул ителә торган өстәмә түләү күләме;

$H_{f_{sd}}$ – спорт әзерлеге үзәкләрендәге физик культура һәм спорт хезмәткәрләренең аерым кулланучылар категорияләре белән эш сәгатьләренең фактагы саны;

$H_n$ – спорт әзерлеге үзәкләрендәге педагогик хезмәткәрләрнең хезмәт хакының база ставкасы өчен әлеге Нигезләмәнең IV бүлегендә билгеләнгән сәгатьләр саны.

3.3. Спорт әзерлеге үзәкләрендә һәм бүлекчәләрендә конкрет эш шартларын исәпкә алып, эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмә түләүләр билгеләнә торган физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазыйфалары исемлеге, сайлап куелган һөнәр берлеге органы яки хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен тәкъдим итәргә вәкаләтле орган белән килештереп, һәр учреждение тарафыннан раслана.

3.4. Спорт исемнәре, спорт разрядлары өчен түләүләр тиешле спорт исемнәре һәм спорт разрядлары бирү өчен кирәкле нормаларны һәм таләпләрне үтәгән өчен спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$B_{szsr} = O_d \times D_{szsr},$$

монда:

$B_{szsr}$ – спорт исемнәре, спорт разрядлары өчен түләүләр;

$O_d$ – спорт әзерлек үзәкләре хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{szsr}$ – спорт исемнәре, спорт разрядлары өчен 5 нче таблицада китерелгән өстәмә түләү күләме.

3.5. Спорт исемнәре, спорт разрядлары өчен түләүләр исем яки разряд бирү турында карар яки боерык датасыннан билгеләнә.

5 нче таблица

Спорт исемнәре, спорт разрядлары өчен өстәмә түләү күләме

| Спорт исеменең атамасы (спорт разряды) | Өстәмә түләү күләме, процент |
|---|---|
| Россиянең халыкара класстагы спорт мастеры | 27,0 |
| Россия спорт мастеры | 20,0 |
| Россия гроссмейстеры | 20,0 |
| Спорт мастерына кандидат | 9,0 |

3.6. Дәүләт бүләкләренә ия булган өчен түләүләр спорт әзерлеге үзәкләренең физик культура һәм спорт хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$B_{pz} = O_d \times D_{pz},$$

монда:

$B_{pz}$ – дәүләт бүләкләренә ия булган өчен түләү;

$O_d$ – спорт әзерлек үзәкләре хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{pz}$ – дәүләт бүләкләренә ия булган өчен өстәмә түләү күләме.

Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикаларның дәүләт бүләкләренә ия булган өчен өстәмә түләү күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең дәүләт бүләкләренә, спорт исемнәренә, Совет Социалистик Республикалар Союзының дәүләт бүләкләренә, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның дәүләт бүләкләренә ия булган өчен өстәмә түләү күләме 7 процент тәшкил итә.

Спорт әзерлеге үзәкләренең физик культура һәм спорт хезмәткәрләренә түләүләр бирелә торган дәүләт бүләкләре, спорт исемнәре исемлеге әлеге Нигезләмәгә кушымтаның 2 нче таблицасында китерелде.

3.7. Дәүләт бүләкләренә ия булган өчен түләү күләмнәрен билгеләү дәүләт бүләге, спорт исеме бирелгән көннән алып башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк дәүләт бүләкләренә, ике һәм аннан да күбрәк спорт исемнәренә ия булган хезмәткәрләргә аларга ия булган өчен түләү хезмәткәрнең сайлавы буенча дәүләт бүләкләренең берсенә билгеләнә.

3.8. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр, профиль буенча эш озынлыгына карап, һөнәри квалификация төркемнәре һәм квалификация дәрәҗәләре яктылыгында стаж буенча төркемнәр нигезендә билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$B_s = O_d \times D_s,$$

монда:

$B_s$ – профиль буенча эш стажы өчен түләү;

$O_d$ – спорт әзерлек үзәкләре хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_s$ – профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме 6 нчы таблицада китерелде.

6 нчы таблица

Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләмнәре

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Стаж буенча төркем | Өстәмә түләү күләме, процент |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Беренче дәрәҗә физик культура хезмәткәрләре вазыйфалары (1 төркем) | беренче – икенче | 2 елдан 5 елга кадәр | 2,5 |
| | | 5 елдан 10 елга кадәр | 3,5 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 4,5 |
| | | 15 елдан артыграк | 5,5 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| Икенче дәрәҗә физик культура хезмәткәрләре вазыйфалары (2 төркем) | беренче – өченче | 2 елдан 5 елга кадәр | 2,5 (3,0*) |
| | | 5 елдан 10 елга кадәр | 3,5 (4,5*) |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 4,5 (5,5*) |
| | | 15 елдан артыграк | 5,5 (6,5*) |
| Өченче дәрәҗә физик культура хезмәткәрләре вазыйфалары (3 төркем) | беренче | 2 елдан 5 елга кадәр | 2,5 |
| | | 5 елдан 10 елга кадәр | 3,5 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 4,5 |
| | | 15 елдан артыграк | 5,5 |
| Дүртенче дәрәҗә физик культура хезмәткәрләре вазыйфалары (4 төркем) | беренче | 2 елдан 5 елга кадәр | 2,5 |
| | | 5 елдан 10 елга кадәр | 3,5 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 4,5 |
| | | 15 елдан артыграк | 5,5 |
| *Физкультура спорт оешмаларының тренеры, методист-инструкторы (шул исәптә өлкән) | | | |

3.9. Эш стажы үзгәргәндә, профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен билгеләү (үзгәртү), әгәр стажны раслый торган документлар оешмада булганда, профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен арттыру хокукын бирә торган стажга ирешкән көннән яки стажны раслый торган кирәкле документны тапшырган көннән алып башкарыла.

3.10. Хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр физик культура һәм спорт хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sr} = O_d \times D_{sr},$$

монда:

$B_{sr}$ – хезмәт нәтиҗәлелеге өчен түләүләр;

$O_d$ – спорт әзерлек үзәкләре хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлы;

$D_{it}$ – хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә түләү күләме.

Хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә түләүнең иң чик күләме 18 процент тәшкил итә.

4. Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр спорт әзерлеге үзәкләренең физик культура һәм спорт хезмәткәрләренә, медицина хезмәткәрләренә билгеле бер вакыт аралыгында хезмәт нәтиҗәләре буенча билгеләнә. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр күләменә йогынты ясый торган төп критерий – ул спорт әзерлеге үзәкләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының иң чик күрсәткечләренә ирешү.

4.1. Спорт әзерлеге үзәкләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары, оешма белән идарә итүнең дәүләти-иҗтимагый характерын тәэмин итүче орган белән килештереп, оешма җитәкчесе тарафыннан раслана. Спорт әзерлеге үзәкләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары күрсәткече һәм түләүләрне гамәлгә ашыру шартлары ел саен оешма алдына куелган бурычлар нигезендә билгеләнә.

4.2. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр күләме, аларны гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары оешманың локаль норматив актлары һәм коллектив шартнамәләре белән билгеләнә.

4.3. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{k_j} = \frac{FOT_k}{\sum_{i=1}^{n}\sum_{j=1}^{m}\left(I_{ij} \times K_i\right)} \times \sum_{i=1}^{n}\left(I_{ij} \times K_i\right),$$

монда:

$B_{k_j}$ – башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр;

$FOT_k$ – башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләргә каралган хезмәт өчен түләү фонды;

$I_{ij}$ – j-хезмәткәр буенча эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләүнең нормалаштырылган i-критерие;

$K_i$ – эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләүнең i-критериенең чагыштырмача үлчәү коэффициенты;

j – хезмәткәр;

i – эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары;

n – эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары саны;

m – спорт әзерлеге үзәкләре хезмәткәрләр саны.

4.4. Эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерийларын нормалаштыру төрле үлчәмдәге нәтиҗәлелек критерийларының чагыштырылуын тәэмин итә. Нормалаштыру эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерие (иң яхшы һәм иң начар) күрсәткечләре диапазонын сайлаудан гыйбарәт, аларның берсе нормалаштырылган критерийның нуль күрсәткеченә, икенчесе берәмлеккә туры килә. Нәтиҗәлелек критериеның факттагы күрсәткече эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерие күрсәткечләре диапазоны чикләрендә булганда, эшчәнлек нәтиҗәлелегенең нормалаштырылган критерие нульдән алып берәмлеккә кадәр булган күрсәткечләрне ала. Нәтиҗәлелек критериеның факттагы күрсәткече иң начар күрсәткечтән түбән булганда, нормалаштырылган критерийның

күрсәткече нульгә, иң яхшысыннан югарырак булганда – берәмлеккә тигез итеп алына.

4.5. Эшчәнлек нәтиҗәлелегенең нормалаштырылган критерий билгесенең эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерие билгесенә бәйле булуы турыдан-туры (уңай динамика критерий билгесе арту белән билгеләнә) һәм киресенчә (уңай динамика критерий билгесе кимү белән билгеләнә) булырга мөмкин.

4.6. Нормалаштырылган критерий, аның билгесе критерий билгесеннән турыдан-туры бәйле булганда, түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$I_i = \frac{FI_i - L_i}{M_i - L_i},$$

монда:

$I_i$ – эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләүнең нормалаштырылган i-нче критерие;

$FI_i$ – эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериеның факттагы күрсәткече;

$M_i$ – эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериеның иң яхшы күрсәткече;

$L_i$ – эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериеның иң начар күрсәткече;

i – эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары;

4.7. Эшчәнлек нәтиҗәлелегенең нормалаштырылган критерие, аның билгесе критерий билгесеннән турыдан-туры бәйле булмаганда, түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$I_i = 1 - \frac{FI_i - L_i}{M_i - L_i},$$

монда:

$I_i$ – эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләүнең нормалаштырылган i-нче критерие;

$FI_i$ – эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериеның факттагы күрсәткече;

$M_i$ – эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериеның иң яхшы күрсәткече;

$L_i$ – эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериеның иң начар күрсәткече;

i – эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары;

4.8. Эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериеның өстенлек дәрәҗәсе үлчәү коэффициентлары белән билгеләнә. Иң өстенлекле критерийга иң зур коэффициент бирелә. Чагыштырма үлчәү коэффициенты түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$K_i = \frac{VK_i}{\sum_{i=1}^{n} VK_i},$$

монда:

$K_i$ – эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләүнең i-критериенең чагыштырмача үлчәү коэффициенты;

$VK_i$ – эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләүнең i нче критериеның үлчәү коэффициенты;

i – эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары;

n – эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары саны.

4.9. Хезмәткәрләр эшчәнлеге нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәү коэффициентларының иң чик җыелма күләме 7, 8 нче таблицаларда күрсәтелде.

7 нче таблица

Медицина хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәү коэффициентларының иң чик җыелма күләме

| Т/с | Вазыйфа исеме | Үлчәү коэффициент-ларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. Урта медицина һәм фармацевтика персоналы вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 1.1. | Медицина статистигы | 35 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 1.2. | Шәфкать туташы | 40 |
| 1.3. | Массаж буенча шәфкать туташы | 40 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | | |
| 1.3. | Фельдшер | 45 |
| 2. Табиблар һәм провизорлар вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| 2.1. | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән табиб-белгечләрдән башка) | 60 |

8 нче таблица

Физик культура һәм спорт хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәү коэффициентларының иң чик җыелма күләме

| Т/с | Вазыйфа исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Үлчәү коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 2. Икенче дәрәҗә физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме (2 төркем) | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 1.1. | Спорт буенча инструктор | беренче | 45 |
| 1.2. | Адаптив физик культура буенча инструктор | беренче | 45 |
| 1.3. | Спортчы-инструктор | беренче | 45 |
| 1.4. | Атны йөрергә өйрәтүче тренер | беренче | 45 |
| 1.5. | Спорт техникасын эксплуатацияләү һәм ремонтлау буенча техник | беренче | 45 |
| 1.6. | Күнекмәләр ясау барышы администраторы | икенче | 50 |
| 1.7. | Тренер | икенче | 50 |
| 1.8. | Адаптив физик культура буенча инструктор-методист | икенче | 50 |
| 1.9. | Адаптив физик культура буенча тренер-укытучы | икенче | 50 |
| 1.10. | Хореограф | икенче | 50 |
| 1.11. | Адаптив физик культура буенча өлкән инструктор-методист | өченче | 55 |
| 1.12. | Адаптив физик культура буенча өлкән тренер-укытучы | өченче | 55 |
| 1.13. | Физкультура-спорт оешмалары инструктор-методисты | икенче | 50 |
| 2. Икенче дәрәҗә физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме (3 төркем) | | | |
| 2.1. | Аналитик (спорт төре яки төрләр төркеме буенча) | беренче | 60 |
| 3. Икенче дәрәҗә физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме (4 төркем) | | | |
| 3.1. | Спорт җыелма командасының баш тренеры (спорт төре буенча) | беренче | 70 |
| 3.2. | Идарә башлыгы (спорт төре яки төрләр төркеме буенча) | беренче | 70 |

4.10. Спорт әзерлеге үзәкләре эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең бертип критерийлары һәм аларның үлчәү коэффициентлары Татарстан Республикасы спорт министрлыгы тарафыннан раслана.

4.11. Спорт әзерлеге үзәкләрендә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллау характерындагы түләүләр фонды төзелә, аның күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOT_k = FOT_{do} \times D_k,$$

монда:

$FOT_k$ – башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләргә каралган хезмәт өчен түләү фонды;

$FOT_{do}$ – хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары (окладлары, хезмәт хакы ставкалары) буенча спорт әзерлеге үзәкләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү фонды;

$D_k$ - башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллау характерындагы түләүләргә хезмәт өчен түләү фонды өлеше.

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллау характерындагы түләүгә хезмәт өчен түләү фондының тәкъдим ителә торган күләме вазыйфаи окладлары (окладлары, хезмәт хакы ставкалары) буенча спорт әзерлеге үзәкләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү фондының 15 проценты күләмендә кабул ителә.

## V. Компенсация характерындагы түләүләр

1. Спорт әзерлеге үзәкләрендә компенсация характерындагы түләүләргә түбәндәгеләр керә:

авыл җирендә эшләгән өчен белгечләргә түләүләр;

инвалидлар һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар белән эшләгән өчен түләүләр;

зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә түләүләр;

нормаль шартлардан читләшкән шартларда (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны) берләштергәндә, югары хезмәт белән эшләгәндә, төнлә эшләгәндә һәм нормаль шартлардан читкә тайпылган башка шартларда эшләр башкарганда) эшләгән өчен түләүләр.

2. Компенсация характерындагы түләүләр, аларны гамәлгә ашыру күләмнәре һәм шартлары хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актлар нигезендә күмәк шартнамәләр, локаль норматив актлар, хезмәт шартнамәсе белән билгеләнә.

3. Авыл җирлегендә эшләгән өчен белгечләргә түләүләр физик культура хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәренә керүче, икенче һәм өченче дәрәҗә физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче, урта медицина һәм фармацевтика персоналының, табибларның һәм провизорларның һөнәри квалификация төркемнәренә керүче медицина хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$B_{sm} = D_{sm} \times S,$$

монда:

$B_{sm}$ – авыл җирендә эшләгән өчен түләүләр;

$D_{sm}$ – авыл җирлегендә эшләгән өчен 1 388,5 сумга тигез түләү күләме;

S – ставкаларның факттагы саны.

Авыл җирендә эшләгән өчен белгечләргә түләүләр шулай ук шәһәр тибындагы поселоклар нигезендә төзелгән түбәндәге шәһәр җирлекләрендә урнашкан оешмалар хезмәткәрләренә дә бирелә:

Апас;

Балтач;

Байлар Сабасы;

Балык Бистәсе.

4. Инвалидлар һәм физик яки акыл үсешендә кимчелекләре булган затлар белән эшләгән хезмәткәрләргә компенсация характерындагы түләүләр икенче дәрәҗә физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче спорт әзерлеге үзәкләре хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$B_{ovz} = O_d \times D_{ovz},$$

монда:

$B_{ovz}$ – эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен түләүләр;

$O_d$ – спорт әзерлек үзәкләре хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{ovz}$ – инвалидлар һәм физик яки акыл үсешендә кимчелекләре булган затлар белән эшләгән өчен 3,5 процентка тигез өстәмә түләү күләме.

5. Зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләгән хезмәткәрләргә һәм нормаль шартлардан тайпылган шартларда эшләгән өчен (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәр (вазыйфалар) берләштергәндә, артык хезмәт эшләгәндә, төнлә эшләгәндә һәм нормаль шартлардан читләшкән башка шартларда эшләр башкарганда) компенсация характерындагы түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kh} = O_b \times D_{kh} \times \frac{H_{fk}}{H_n},$$

монда:

$B_{kh}$ – компенсация характерындагы түләүләр;

$O_b$ – спорт әзерлеге үзәкләре хезмәткәрләренең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган база оклады күләме;

$D_{kh}$ – Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә кабул ителә торган компенсация характерында түләү өчен өстәмә түләү күләме;

$H_{fk}$ – законнарда компенсация характерындагы түләүләр каралган, фактта эшләнгән вакыт (ставка);

$H_n$ – спорт әзерлеге үзәкләре хезмәткәрләренең хезмәт хакының база ставкасы өчен әлеге Нигезләмәнең III бүлегендә билгеләнгән сәгать нормасы.

6. Нормаль шартлардан читкә тайпылган шартларда (төрле квалификацияле эшләр башкарганда, һөнәрләр (вазыйфалар) бергә эшләгәндә, эштән тыш эшләгәндә, төнге вакытта эшләгәндә һәм нормаль шартлардан читкә тайпылучы башка шартларда эшләгәндә) эшләгән өчен түләүләр төнге вакытта эшләгән һәр сәгать өчен билгеләнә, ул нормаль шартлардагы эш белән чагыштырганда югары күләмдә, әмма

законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән билгеләнгән күләмнәрдән түбән булмаган күләмнәрдә түләнә.

Хезмәткәрне аңа билгеләнгән ял көнендә яки эш көне булмаган бәйрәм көнендә эшкә җәлеп иткән очракта, эшләгән өчен кимендә ике тапкыр күбрәк күләмдә, вазыйфаи оклад алучы хезмәткәрләргә, әгәр эш ял һәм эш көне булмаган бәйрәм көнендә айлык эш вакыты нормасы кысаларында башкарылса, окладка өстәп кимендә бер көнлек күләмдә яки бер сәгатьлек база ставкасы күләмендә һәм, әгәр эш айлык нормадан күбрәк башкарылса, база окладка өстәп кимендә ике сәгатьлек күләмдә яки көндезге ставка күләмендә түләнә.

7. Ял көнендә яки эш көне булмаган бәйрәм көнендә эшләгән хезмәткәрнең теләге буенча аңа башка ял көне бирелергә мөмкин. Бу очракта эш көне булмаган бәйрәм көнендә эшләгән өчен бер генә күләмдә түләнә, ә ял көне өчен түләү каралмый.

8. Зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә мәшгуль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү окладлары (вазыйфаи окладлар), хезмәт шартлары нормаль булган төрле эшләр өчен билгеләнгән хезмәт хакы ставкалары белән чагыштырганда, хезмәт шартларын махсус бәяләүгә нигезләнеп, кимендә 4 база оклады күләмендә билгеләнә.

## VI. Оешма җитәкчесенең, оешма җитәкчесе урынбасарының, баш бухгалтер һәм баш инженерның хезмәт хакын билгеләү тәртибе

1. Оешма җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының, баш бухгалтерларның һәм баш инженерларның хезмәт хаклары вазыйфаи окладлардан компенсация һәм стимуллау характерындагы түләүләрдән тора.

2. Спорт әзерлеге үзәкләре җитәкчеләренең вазыйфаи оклады гамәлгә куючы тарафыннан елга бер тапкыр агымдагы елның 1 сентябренә яки хезмәт өчен түләү төркеменә бәйле рәвештә оешма төзелгән датага карата билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$O_d = O_b \times S,$$

монда:

$O_d$ – спорт әзерлеге үзәкләре җитәкчеләренең вазыйфаи оклады;

$O_b$ – җитәкчеләрнең база окладына күләме;

S – ставкаларның факттагы саны.

Спорт әзерлеге үзәге җитәкчесенең хезмәте өчен түләү буенча төркем анда шөгыльләнүчеләр саныннан чыгып билгеләнә.

3. Спорт әзерлеге үзәкләре җитәкчеләре урынбасарларының, баш бухгалтерларының һәм баш инженерларының вазыйфаи окладлары әлеге оешмалар җитәкчеләренең вазыйфаи окладларыннан 20 – 30 процентка түбәнрәк билгеләнә.

4. Җитәкчеләрнең хезмәте өчен түләү төркеме, җитәкчеләрнең база һәм вазыйфаи окладлары күләмнәре 9 нчы таблицада күрсәтелде.

5. Спорт әзерлеге үзәген гамәлгә куючы, эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, спорт әзерлеге үзәге җитәкчесенә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллау характерындагы түләүләр билгели ала.

Спорт әзерлеге үзәге җитәкчесенә стимуллау характерындагы түләүләр 9 нчы таблицада күрсәтелде.

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллау характерындагы түләүләр спорт әзерлеге үзәге җитәкчесенә ай саен, бер ел өчен эш йомгаклары буенча, мөһим һәм аеруча мөһим йөкләмәләрне үтәгән өчен түләнергә мөмкин.

6. Спорт әзерлеге үзәге җитәкчесе, эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерга, баш инженерга стимуллау характерындагы түләүләр билгели ала. Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерга, баш инженерга стимуллау характерындагы түләүләр ай саен, квартал саен, еллык эш йомгаклары буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәгән өчен башкарылырга мөмкин. Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллау характерындагы түләүләрнең иң чик дәрәҗәсе спорт әзерлеге үзәге җитәкчесенең башкарылган эшләр сыйфаты өчен стимуллау характерындагы түләүләрнең 70 проценты күләмендә билгеләнә.

9 нчы таблица

Спорт әзерлеге үзәкләре җитәкчеләренең башкарыла торган эшләренең сыйфаты өчен база окладлары һәм стимуллау характерындагы түләүләр күләме

| Җитәкченең хезмәте өчен түләү буенча төркем | Күләм күрсәткеченең зурлыгы (агымдагы елның 1 гыйнварына карата дәүләт биреме нигезендә хезмәткәрләр саны), ставка | База оклады, сум | Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллау характерындагы түләүләр, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 1 – 200 | 39 000 | 4 000 |
| 2 | 201 һәм аннан да югарырак | 44 000 | 6 000 |

7. Спорт әзерлеге үзәкләре җитәкчеләре, җитәкче урынбасарлары, баш бухгалтерлары, баш инженерлары эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең бертип критерийлары һәм аларның үлчәү коэффициентлары Татарстан Республикасының спорт әзерлеге үзәкләре өчен җавап биргән тармак министрлыклары тарафыннан раслана.

8. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_k = B_c \times K_{vk},$$

монда:

$B_k$ – аларның эшчәнлеге нәтиҗәләрен исәпкә алып, башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллау характерындагы түләү;

$B_c$ – 9-нчы таблицада күрсәтелгән стимуллау характерындагы түләүләрнең күләме;

$K_{vk}$ – сыйфат критерийларын үтәү коэффициенты.

9. Компенсация характерындагы түләүләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә спорт әзерлеге үзәкләре җитәкчеләре, аларның урынбасарлары, баш бухгалтеры өчен билгеләнә.

## VII. Спорт әзерлеге үзәкләренең хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру һәм куллану тәртибе

Спорт әзерлеге үзәкләренең хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру агымдагы финанс елына спорт әзерлеге үзәкләренең финанс чыгымнары нормативы, кулланучылар һәм хезмәт күрсәтүләр саны нигезендә билгеләнгән акча күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм спорт әзерлеге үзәкләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында чагылдырыла.

2. Әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән хезмәт окладларын, компенсация, стимул бирү һәм социаль характердагы түләүләрне исәпләү спорт әзерлеге үзәкләре хезмәткәрләренә (эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәр-квалификация төркемнәрен кертеп) спорт әзерлеге үзәкләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында яки бюджет сметасында агымдагы финанс елына хезмәт өчен түләүгә каралган акча исәбеннән гамәлгә ашырыла.

3. Тиешле чорга (айга, кварталга, елга) хезмәт өчен түләү фондында спорт әзерлеге үзәкләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акча спорт әзерлеге үзәкләренең әлеге Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән локаль норматив актлары нигезендә стимуллау характерындагы түләүләргә җибәрелергә мөмкин.

Хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы булганда, стимуллау характерындагы түләүләр кайсы вазыйфаларның һөнәр-квалификация төркеме буенча хезмәт өчен түләү фондында экономияләнгән акча барлыкка килгән булса, шул вазыйфалар төркемендәге хезмәткәрләргә (эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәр-квалификация төркемнәре хезмәткәрләрен кертеп) түләнә.

Тиешле чорга хезмәт өчен түләү фондының экономияләнгән акчасы исәбеннән спорт әзерлеге үзәгенең хезмәт нормаларын (хезмәт йөкләмәләрен) үтәгән хезмәткәренә (спорт әзерлеге үзәгенең педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләреннән һәм икенче дәрәҗә физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләреннән, җитәкчесеннән тыш) әлеге тиешле чорда эшләнгән эш вакыты нормасын исәпкә алып бирелгән сттимуллау характерындагы түләү күләме агымдагы елның 1 гыйнварына «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның

19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең өч минималь күләменнән арта алмый.

Хезмәт өчен түләү фондын экономияләү исәбеннән спорт әзерлеге үзәге җитәкчесенә кызыксындыру түләве күләме спорт әзерлеге үзәгенең гамәлгә куючысы тарафыннан билгеләнә.

Спорт әзерлеге үзәкләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында хезмәт өчен түләү фондында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары (түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәре кертеп) хисабына экономияләнеп барлыкка килгән акчаны файдалану өчен җаваплылык спорт әзерлеге үзәкләре җитәкчесенә йөкләнә.

Татарстан Республикасында
дәүләт спорт әзерлеге
үзәкләре хезмәткәрләренең
хезмәте өчен түләү шартлары
турындагы нигезләмәгә
кушымта

1 нче таблица

Медицина хезмәткәрләренә стимуллау түләүләре бирелә торган
дәүләт бүләкләре исемлеге

| Т/с | Дәүләт бүләге исеме |
|---|---|
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре | |
| 1.1. | Россия Федерациясенең Атказанган табибы |
| 1.2. | Россия Федерациясенең Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре |
| 1.3. | Россия Федерациясе сәламәтлек саклау отличнигы |
| 2. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре | |
| 2.1. | Татарстан Республикасының Атказанган табибы |
| 2.2. | Татарстан Республикасының Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре |

2 нче таблица

Физик культура һәм спорт хезмәткәрләренә стимуллау характерындагы түләүләр
бирелә торган Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет
Социалистик Республикалар Союзының, Совет Социалистик Республикалар
Союзы составындагы союздаш һәм автоном республикаларның дәүләт бүләкләре,
спорт исемнәре исемлеге

| Т/с | Мактаулы исем, спорт исеме, ведомство бүләге исеме |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, спорт исемнәре | |
| 1.1. | Россия Федерациясенең Атказанган физик культура хезмәткәре |
| 1.2. | Россиянең Атказанган спорт мастерлары |
| 1.3. | Россиянең Атказанган тренеры |
| 1.4. | Россиянең мактаулы спорт судьясы |
| 1.5. | Россиянең халыкара класстагы Атказанган спорт мастеры |
| 1.6. | Россиянең халыкара класстагы спорт мастеры |
| 1.7. | Россия спорт мастеры |
| 1.8. | Россия гроссмейстеры |
| 1.9. | Россиянең мактаулы спорт судьясы |
| 2. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре | |
| 2.1. | Татарстан Республикасының Атказанган физик культура хезмәткәре |

| 1 | 2 |
|---|---|
| 2.2. | Татарстан Республикасының Атказанган тренеры |
| 3. Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре | |
| 3.1. | СССРның Атказанган спорт мастеры |
| 3.2. | СССРның Атказанган тренеры |
| 3.3. | СССРның спорт мастеры |
| 3.4. | СССРның халыкара класстагы спорт мастеры |
| 3.5. | РСФСРның Атказанган тренеры |
| 3.6. | СССРның гроссмейстеры |
| 4. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 4.1. | Атказанган физкультура һәм спорт эшлеклесе |
| 4.2. | Атказанган спорт эшлеклесе |
| 4.3. | Атказанган физик культура эшлеклесе |
| 4.4. | Атказанган физик культура һәм спорт хезмәткәре |
| 4.5. | Атказанган тренер |
| 5. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 5.1. | Атказанган физкультура һәм спорт эшлеклесе |
| 5.2. | Атказанган физик культура һәм спорт хезмәткәре |